ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

№ 4 Иске Урыссу ав. 2020 елның 16 марты

Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл
җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне
хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер
өлешен Ютазы муниципаль районы
җирле үзидарә органнарына
тапшыру турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 15 маддәсендәге 4 өлеше, «Урыссу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Урыссу авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Ютазы муниципаль районы Советына Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына Урыссу авыл җирлеге башкарма комитеты вәкаләтләренең җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрен хәл итүне тапшыру мәсьәләсен тәкъдим итәргә:

- җирлекләрнең мөлкәтен исәпкә алуны тәэмин итү һәм оештыру, аның реестрын алып бару, шул исәптән торак фонды объектлары, җирлекләрнең муниципаль милек реестрыннан өземтәләр бирүне;

- гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә һәм шартларда, шул исәптән мөлкәтне хуҗалык алып бару һәм муниципаль бюджет учреждениеләренә оператив идарә итү хокукында беркетү, шулай ук алар арасында мөлкәтне яңадан бүлү буенча;

- җирлек милкендә булган муниципаль милек реестрын, шулай ук Ютазы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеген урнаштыру вәкаләтләре.

2. Ютазы муниципаль районы Советы әлеге карарның беренче өлешендә күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Урыссу авыл җирлеге башкарма комитеты:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы белән әлеге карарның беренче өлешендә күрсәтелгән вәкаләтләрне кушымта нигезендә типлаштырылган форма нигезендә тапшыру турында килешү төзергә, төзелә торган килешүләрнең

гамәлдә булуы 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җирлекнең бюджет-финанс комиссиясенә йөкләргә.

Уруссу авыл җирлеге башлыгы
вазифаларын башкаручы Ф.Г. Әминова

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Урыссу авыл җирлеге карарына
Кушымта 16.03.2020 № 4

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына башкарма комитет вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында__________________шәһәр (авыл) җирлеге башкарма комитеты**

**КИЛЕШҮЕ**

__________ шәһәр (авыл) җирлеге башкарма комитеты тарафыннан алга таба «җирлек башкарма комитеты» дип аталучы шәһәр (авыл) җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе йөзендә ___________, бер яктан, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы һәм алга таба «Палата» дип аталган «Палата», палата рәисе йөзендә____________, нигезләмә нигезендә эш итүче, икенче яктан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 15 маддәсендәге 4 өлешенә таянып, түбәндәге эчтәлектә килешү төзеделәр:

## 1. Килешү предметы

1.1. Әлеге килешү җирлек башкарма комитеты вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны палатага тапшыруны беркетә.

1.2. Җирлек башкарма комитеты палатага түбәндәге вәкаләтләрне тормышка ашыруны тапшыра:

- җирлекләрнең мөлкәтен исәпкә алуны тәэмин итү һәм оештыру, аның реестрын алып бару, шул исәптән торак фонды объектлары, җирлекләрнең муниципаль милек реестрыннан өземтәләр бирүне;
- гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә һәм шартларда, шул исәптән мөлкәтне хуҗалык алып бару һәм муниципаль бюджет учреждениеләренә оператив идарә итү хокукында беркетү, шулай ук алар арасында мөлкәтне яңадан бүлү буенча;
- Ютазы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында җирлекләр милкендә булган муниципаль милек реестрын урнаштыру буенча.

1.3. 1.2 өлешендә күрсәтелгән вәкаләтләр, әлеге Килешү палатага бюджетара трансфертлар тапшырмыйча гына тапшырыла.

## 2. Ике якның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Палата әлеге килешүнең 1 бүлеге һәм гамәлдәге законнар нигезендә җирлек башкарма комитеты тарафыннан үзенә тапшырылган вәкаләтләрне башкара.

2.2. Яклар әлеге килешүне гамәлгә ашыру кысаларында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы закон һәм норматив хокукый актларында каралган вакытларда һәм күләмнәрдә мәгълүмат алмашырга бурычлы.

2.3. Җирлек башкарма комитеты район башкарма комитетына тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлешен контрольдә тота ала.

## 3. Килешүнең гамәлдә булу вакыты, нигезләре һәм гамәлдә булуын туктату тәртибе

3.1. Әлеге килешү аңа кул куелган көннән алып һәм ______елга кадәр гамәлдә.

3.2. Әлеге килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

3.2.1. Ике якның килешүе буенча.

3.2.2. Берьяклы тәртиптә:

әгәр вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мөмкин булмаган булса, шул исәптән Россия Федерациясе законнары һәм (яисә) Татарстан Республикасы законнары үзгәргән очракларны да кертеп;

- палатаның үзенә тапшырылган вәкаләтләрен тиешенчә башкармавы (яки бөтенләй башкармавы) очрагында, җирлек башкарма комитеты инициативасы буенча бер айга икенче якка моның турыда хәбәр итү шарты белән.

3.3. Килешүне өзү язма рәвештә рәсмиләштерелә.

3.4. Әгәр яклар әлеге килешүнең 4.1 өлешендә күрсәтелгән вакыт узганнан соң утыз көн эчендә килешүне өзү нияте турында белдермиләр икән, килешү яңа вакытка төзелгән дип санала.

## 4. Ике якның җаваплылыгы

4.1. Яклар гамәлдәге законнар нигезендә әлеге килешүдә каралган бурычларны тиешенчә үтәмәгән өчен җавап тоталар.

4.2. Палата тарафыннан аңа тапшырылган вәкаләтләрне тиешенчә башкармау фактын билгеләү әлеге килешүнең берьяклы өзелүенә нигез булып тора.

4.3. Әлеге килешүдә каралмаган якларның җаваплылык чаралары Россия Федерациясе территориясендә гамәлдә булган граждан законнары нормалары нигезендә кулланыла.

## 5. Башка сораулар

5.1. Яклар үзара килешүе буенча яисә гамәлдәге закон таләпләре нигезендә әлеге килешүгә яклар кул куйганнан соң, әлеге килешүнең аерылгысыз өлеше булып торган язма рәвештә үзгәрешләр һәм (яки) өстәмәләр кертелергә мөмкин.

5.2. Әлеге килешүне үтәгәндә яклар тарафыннан җайга салынмаган бәхәсләр һәм каршылыклар гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә каралырга тиеш.

5.3. Әлеге килешү 2 (ике) нөсхәдә, һәр як өчен бер нөсхәдә, тигез юридик көчкә ия булган яклар өчен төзелде.

## 6. Ике якның адресы һәм алар турында мәгълүматлар

Татарстан Республикасы ___________шәһәр (авыл) җирлеге башкарма комитеты

Адрес:___________________________________________________________
_________________________________________________________________

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы

Адрес:___________________________________________________________
_________________________________________________________________

## 7. Ике якның имзалары

| **"Җирлек" исеменнән** | **"Палата" исеменнән** |
| --- | --- |
| ______________________ | ______________________ |
| (имза) | (имза) |
| М.П. | М.П. |